**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2022 Балык Бистәсе штп. № 365пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.09.2020 №193пи карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында иреклеләр хәрәкәтен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы яшьләр министрлыгының “Муниципаль программаларны актуальләштерү турында"гы 03.11.2022 №5507/исх-РС хаты нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.09.2020 №193пи карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында доброволецлыкны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) программа паспортын түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигезләмәләр | «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында»30.12.2020 № 489-ФЗ Федераль закон; «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 19.10.1993 ел, №1983-XII Татарстан Республикасы Законы; «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» Россия |

| | |
|---|---|
| | Федерациясе Президентынын 04.02.2021 ел, №68 Указы; «Мәгариф» милли проектының «Социаль активлык», «Патриотик тәрбия» Федераль проектлары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 17.03.2011 № 204 карары |

1.2) " Программа бурычлары» пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

"гамәлдәге законнарны камилләштерү һәм ирекле эшчәнлекне норматив - хокукый жайга салуның тулы системасын формалаштыру, шул исәптән Татарстан Республикасы ирекләләр хәрәкәтен үстерү буенча ведомствоара совет катнашында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре дәрәҗәсендә дә;

- Татарстан Республикасында гамәлдәге ирекләләр (волонтерлар) берләшмәләренә ярдәм итүгә, шулай ук яңа ирекләләр (волонтерлар) берләшмәләрен булдыруга ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итү;

- ирекләләр (волонтерлык)үсешенә дәүләт һәм муниципаль ярдәм күрсәтү системасын булдыру;

- җәмгыятьтә ярдәмнең үсешен тәэмин итү һәм халыкның ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуын киңәйтү, шулай ук гражданнарның коммерцияле булмаган секторга ышанычын арттыру;

- ирекләләр (волонтерлар) һәм ирекле (волонтерлар) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм профессиональлеген күтәрүгә ярдәм итү;

- фәнни җәмәгатьчелекне ирекле берләшмәләр һәм үзәкләр эшчәнлегенә тарту, ирекле (волонтерлар) инициативаларын тормышка ашыру һәм бәяләү;

-төрле ирекләләр берләшмәләре, оешмалар һәм башка иҗтимагый берләшмәләр, һәм ирекле хезмәт кулланган коммерцияле булмаган оешмалар, корпоратив волонтерлык һәм хәйрия проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыручы бизнес-структуралар арасында партнерлык мөнәсәбәтләре системасын камилләштерү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Л. Исланов